**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче-Тамак авыл җирлеге составына керүче Хуҗи авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

# КАРАР

17 ноябрь, 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Теләнче Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Теләнче Тамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 47/2 номерлы карары нигезендә 2025 елның 17 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча Хужи авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2026 елда яшәү урыны буенча Теләнче Тамак авыл җирлеге Хуҗи авылы территориясендә теркәлгән һәр бәлигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү, контракт буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, Теләнче Тамак авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

«- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү.»

«ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 61 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 34 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

**«Әйе»** позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 34 кеше тавыш бирде;

**«Юк»** позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче-Тамак авыл җирлеге Хуҗи авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2026 елда яшәү урыны буенча Теләнче Тамак авыл җирлеге Хуҗи авылы территориясендә теркәлгән һәр бәлигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү, контракт буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, Теләнче Тамак авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә

«- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү.»

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Тукай муниципаль районы Теләнче-Тамак авыл җирлеге Хуҗи авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Теләнче-Тамак авыл җирлеге Хуҗи авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Теләнче-Тамак авыл җирлеге Башлыгы Р.Ш. Назметдинов